КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 12 апрель г.Казань № 223

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру чаралары турында» 2021 ел, 20 март, 150 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру чаралары турында» 2021 ел, 20 март, 150 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 28 июль, 905 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты» сүзләрен «Республикасында «Кадрлар» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт базары белән идарә итү» федераль проекты» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты» сүзләрен «Республикасында «Кадрлар» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт базары белән идарә итү» федераль проекты» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты»

сүзләрен «Республикасында «Кадрлар» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт базары белән идарә итү» федераль проекты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проектының максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләрен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 март, 150 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 12 апрель, 223 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасында «Кадрлар» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт базары белән идарә итү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны (алга таба – субсидия) тоту тәртибен билгели.

2. Субсидия максатчан билгеләнешкә ия һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга тотыла:

а) «Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территорияләрендә эшчәнлек алып баручы халыкны эш белән тәэмин итү буенча территориаль үзәкләр (алга таба – Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) урнашкан биналарга һәм бүлмәләргә агымдагы ремонт ясау;

б) Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге биналарын һәм бүлмәләрен җиһазлау һәм бердәм фирма стилендә эшләү.

3. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) ачылган Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетына керә.

4. Субсидияне тоту әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, бюджет йөкләмәләре

лимитлары һәм финанслауның иң чик күләмнәре турында мәгълүмат Казначылыктан алынган көннән алып җиде эш көне эчендә, финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җиткерә.

6. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән төзелгән субсидия бирү турында килешүдә (алга таба – Субсидия бирү турында килешү) билгеләнгән субсидия акчасын файдалану нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү өчен җавап бирә.

7. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Субсидия бирү турындагы килешүгә теркәлгән кушымталарда китерелгән формалар буенча финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисаплар тапшыра.

8. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән срокларда Субсидия бирү турындагы килешүгә теркәлгән кушымталарда бирелгән формалар буенча Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә хисаплар тапшыра.

9. Субсидия акчасыннан максатчан файдаланмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

10. Субсидия бирү турындагы килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, субсидияне федераль бюджетка кире кайтару Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү турында» 2014 ел, 30 сентябрь, 999 нчы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә каралган тәртиптә һәм шартларда гамәлгә ашырыла.

11. Субсидия акчасыннан максатчан файдалануны контрольдә тоту Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.